**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫН ХӘЛ ИТҮ**
**2025 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында**
**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы**
**Сармаш-Баш авыл җирлегенең Сармаш-Баш торак пунктында**
**(торак пункт территориясе өлешендә) гражданнар җыены үткәрү нәтиҗәләре турында**

2024 елның 21 ноябре № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Сармаш-Баш авыл җирлеге Сармаш-Баш торак пункты ( торак пункт территориясе өлеше) гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Сармаш-Баш авыл җирлегенең Сармаш-Баш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2025 елда 600 (алты йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә, шул исәптән көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, I төркем инвалидларыннан, ялгыз өлкән яшьтәге гражданнардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш.

2. Җыелган сумманы җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга:

- торак пункт эчендәге юлларга вак таш җәю (Үзәк урам)
-урам яктырткычларын светодиодлы лампочкаларга алыштыру һәм ремонтлау;

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Сармаш-Баш авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Зәй муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» урнаштырырга (PRAVO.TATARSTAN.RU) 7 көн дәвамында (Сармаш-Баш авыл җирлеге Уставының 69 п.5 статьясы) кабул ителгән көннән..

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Сармаш-Баш авыл җирлеге башлыгы ________________ Р.М.Фәсхетдинов
(имза) (имза расшифровкасы)